| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 29 » ноябрь 2024 ел № 115

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының «Милеккә салым турында»гы 29.06.2022 елының № 49 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге Советының «Мөлкәткә салым турында» 2022 елның 29 июнендәге 49 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.4. пунктта «, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга,шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Кече Лызи авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов